ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЭШЕР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423357, Иске Кәшер авылы, Комсомол ур. 4а,
тел. (885559)4-86-36 E –mail : Sksr.sar@.tatar.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТА
СОВЕТ СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГ
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423357, с. Старый Кашир, ул. Комсомола, 4а,
тел. (885559) 4-86-36 E-mail: Sksr.sar@.tatar..ru

ОКПО 93068309 ОГРН 1021601312215 ИНН/КПП 1636001259/163601001

КАРАР

"19 сентябрь 2017 ел № 19 Иске Кәшер авылы

## Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 11,12 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ.:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

«2018 елда Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән килешәсезме?:

җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру;;

-җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру(урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту); ;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту .

«ӘЙЕ,»

ЮК"

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы Р. Н. Дәүләтҗанов